# Педагогика фәне үсештә

**М. МӘХМҮТОВ,**
СССР Педагогия фәннәре академиясенең
профтехпедагогика фәнни-тикшеренү
институты директоры, академик

«Бөтендөнья капитализмы һәм Россиянең 1905 ел хәрәкәте Азияне тәмам уятты. Изелгән, урта гасыр торгынлыгында кыргыйланган йөзләрчә миллион халык яңа тормышка һәм кешенең элементар хокуклары өчен, демократия өчен көрәшкә уянды» [1],— дип язды В. И. Ленин.

1917 елда тарихта яңа чор башланды. Бөек Октябрь татар халкы тормышына да зур үзгәрешләр алып килде. Берничә дистә ел эчендә ул урта гасырның схоластик мәктәбеннән университетка кадәр юл үтте, элекке сука һәм сабан урынына зур йөк күтәрешле «КамАЗ» машиналары, «Ил-62» һава лайнерлары эшләп чыгара башлады.

Хәзер республика халык хуҗалыгында 255 меңнән артык инженер, 40 мең техник эшли. 1913 елда бөтен Россиядә 14 мең чамасы фәнни хезмәткәр булган. Бүген Совет Татарстанында гына да алар 18 меңнән артык.

Моңа ничек ирешелгән? Үтә кыска вакыт эчендә шундый сикереш ясауның сере нәрсәдә? Әлбәттә, политика һәм экономикада. Ләкин мәгърифәт һәм аның фәне — педагогиканың да әһәмияте зур.

Белгәнебезчә, патша Россиясендә рус булмаган халыкларның күпчелегендә фән-ни-педагогик фикер XIX йөзнең икенче яртысында формалаша башлый. Ул чор капитализмның барлыкка килүе, сәүдәнең көчәюе һәм шуның нәтиҗәсендә мәгариф эшенең шактый активлашуы белән

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 нче басмадан тәр-жемә, 15 т., 67 б.

характерлана. Завод-фабрикаларда, сәүдә һәм финанс учреждениеләрендә эшләр өчен укый-яза белгән эшчеләр һәм хезмәткәрләр әзерләүгә ихтыяҗның арта баруы милли мәктәпләргә дә реформа үткәрүне көн тәртибенә куя. Мәктәп-мәдрәсәләрдә рус телен өйрәнүгә омтылыш көчәя, табигать фәннәре, тарих, география һ. б. предметлар кертелә. Реакцион дин әһелләренең

лык күрсәтүенә дә карамастан, прогрессив фикерле эшлеклеләр җәдит мәктәпләре ачалар. Болар барысы да яңа укыту планнары һәм программалар, дәреслекләр, методик ярдәмлекләр төзүне таләп итә.

Татарларда педагогик фикер үсешенең икенче чыганагы һәм стимулы итеп рус педагогика фәнен санарга кирәк. Тарихи шартларга бәйле рәвештә төрле халыкларда педагогик фикер төрле вакытта активлаша башлый. Мәсәлән, рус педагоглары һәм Казан галимнәре йогынтысында татарларда дөньяви белем тарафдарлары үсе0 чыга, Ульяновлар гаиләсенең турыдан-туры йогынтысында һәм ярдәмендә чуваш укытучысы И. Яковлев күренекле педагог булып танылa. XIX гасырда педагогик белемнәр таратуда рус миссионерлары да билгеле бер роль уйный. Алар мөселманнар арасында, бигрәк тә крәшен татарлары арасында зур эш алып баралар: мәктәпләр ачалар, рус теле өйрәтәләр, алар өчен дә-реслекләр төзиләр.

Татарларда дөньяви белем алуга омтылышның көчәя баруына 1804 елда ачылган Казан университеты да зур этәргеч ясый. Рус фәне һәм культурасының иң көнчыгыш үзәге саналган бу уку йортында 19 ел буе Н. И. Лобачевский ректор була, Лев Толстой шунда укырга керә, Максим Горький биредә белем алу турында хыяллана, Илья Николаевич Ульянов монда фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала... Казан марксизмны тарату үзәкләренең берсе була, Ленинның революциягә үз юлын биредә башлавы да очраклы түгел.

Университет мөгаллимнәре И. Хәлфин, М. Мәхмүдов, Х. Фәезханов, К. Насыйри һәм башкалар, беренчеләрдән булып, руслар өчен татар теле

дәреслекләре һәм программалары, татарлар өчен рус теле дәреслекләре һәм программалары, шулай ук грамматикадан ярдәмлекләр, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр, тел укыту буенча күп кенә методик кулланмалар төзиләр. Узган гасыр ахырына инде К. Насыйри К. Д. Ушинскийның дидактик системасы тарафдары һәм пропагандисты булып җитлегә.

1876 елда Казанда татар укытучылар мәктәбенең ачылуы татар интеллигенциясе вәкилләре арасында педагогик фикер таратуда гына түгел, бәлки аларда революцион аң тәрбияләүдә гаять зур- роль уйный. Рус теле һәм әдәбиятын өйрәнү, педагогика фәне белән танышу татарларда әкренләп демократик һәм марксистик әдәбиятка юл ача. Танылган татар педагог-революционер-лары Г. Колахметов, X. Ямашев, педагог-марксист Г. Сәйфетдинов һәм башкалар шушы уку йортында белем ала. Алар XX йөз башында татар интеллигенциясе һәм яшьләре арасында алдынгы педагогик идеяләрне таратучылар булып әвереләләр.

1907 елда X. Ямашев редакциясендә чыга башлаган большевистик «Урал» газетасында Да марксистик педагогика мәсьәләләре шактый киң яктыртылган. X. Ямашевның дусты Галимҗан Сәйфетдинов 1912—1914 елларда Н. К. Крупская белән хат алышкан. Педагогика проблемалары буенча ул язган күп кенә публицистик мәкаләләрдә Н. К. Крупская карашлары чагылыш таба. Педагсн-марксистның хатлар алышуы татар халык педагогикасында марксистик идеяләр формалашуына йогынты ясаган. Укучылар һәм татар эшчеләре арасында ленинчыл «Искра»ны пропагандалаган укытучылар, агалы-энеле Колахметовлар бу турыда хәбәрдар булганнар[2].

Танылган совет педагогы М. X. Корбан-галиевнең революциягә кадәрге хезмәтләрендә үк билгеле бер дәрәҗәдә марксистик идеяләр урын ала, укыту һәм тәрбиянең буржуаз идеяләренә сыйнфый позициядән чыгып

---

[2] Ханбиков Я. И. XI—XX йөзләрдә татар халкында педагогик фикер үсешенең төп юнәлешләре. Докторлык диссертациясе автореферады (рус телендә), М., 1968, 12—13 б.

анализ ясала. Күренекле татар революционеры, язучы Г. Ибраһимовның эшчән-леге дә педагогик фикер формалашуга җитди йогынты ясый[3].

Совет Татарстанының танылган педагоглары һәм татар совет мәктәбен башлап оештыручылар Ш. Әхмәдиев, М. Корбанга-лиев, Г. Ибраһимов, М. Фазлуллин, В. Горохов, Н. Надиев, Г. Сәгъди һ. б. марксистик педагогика классигы Н. К. Крупская идеяләренең шифалы йогынтысын тоеп хезмәт итәләр.

Шулай да 1917 елга кадәр татарларда педагогика теориясе буенча махсус хезмәтләр бик аз була. Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң, Владимир Ильич «бөтен бер переворот, бөтен халык массасының культура үсешендә бөтен бер полоса»[4] дип бәяләгән культура революциясе башлана. Аны тормышка ашыру өчен бик күп киртәләрне җиңәргә, җимереклекне бетерергә, халык хуҗалыгын торгызырга, шовинизмга һәм милләтчелеккә каршы кискен көрәш алып барырга туры килә. Әмма «партия шуңа иреште, интернационализм бер төркем коммунистлар идеалыннан барлык милләтләрдән һәм халыклардан булган миллионнарча һәм миллионнарча совет кешеләренең тирән инануына әверелде. Бу — иҗтимагый аңда чын революцион переворот һәм аның әһәмиятен бәяләп бетерүе кыен»[5].

.

Бөек Октябрь революциясеннән соң ук яңа педагогика фәне юк, ә искесен яңа җәмгыятькә механик рәвештә күчерергә ярамый иде. Ул елларда Н. К. Крупская, иске педагогиканы элекке хәлендә куллану мөмкин түгел[6], дип ассызыклап күрсәтте. Элекке мирастан яңа социалистик педагогика эчтәлегенә органик рәвештә кереп китәрлек иң мөһим өлешләрен генә сайлап алу, бер үк вакытта педагогика һәм мәктәпләрнең үткәне турындагы белемнәрдәге бушлыкны бетерү бурычы да

---

[3] Мансур Хәсанов. Галимҗан Ибраһимов. Казан, 1969, 309—330 б.
[4] В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 нче басмадан тәрҗемә, 33 т., 455 б.
[5] Л. И. Брежнев. Ленин юлыннан, 4 т., 69 б.
[6] Крупская Н. К. Педагогические сочинения, 3 т.. с. 255.

куелды. Әмма ул чорда әле яңа төзелгән милли республикаларда үз галим-педагогларын хәзерләү мөмкинлеге дә булмаган. Аннары ликбез һәм башлангыч мәктәпләрнең ихтыяҗлары да башка иде. Россиянең хокуксыз халыкларына мәктәп һәм мәгариф үсеше тарихын соңыннан гына өйрәнү мөмкинлеге туды. Элекке милли окраиналарда педагогика фәне Совет властеның беренче елларында, нигездә, гамәли юнәлештә үсте. Бу чорда кайбер халыкларда ана теле һәм рус теле буенча оригиналь дәреслекләр төзелде, икенчеләрендә мәктәпләр челтәре үзгәртеп корылды, гамәлдәге дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр камилләштерелде. Барлык халыклар да рус телен өйрәнү юлларын актив эзли башладылар. Мөселман халыклары исә дини мәдрәсәләр нигезендә дөньяви мәктәпләр коруга керештеләр.

Рус интеллигенциясенең ярдәме белән барлык союздаш һәм автономияле республикаларда гаҗәеп зур эш башкарылды. Профессорлардан В. М. Горохов, Я. И. Хан-биков, М. 3. Тутаев монографияләре һәм тугандаш республика галимнәренең хезмәтләре СССР халыкларында мәктәп, мәгариф һәм педагогик фикер үсеше тарихын тикшерү өчен дә җирлек булып хезмәт итте. Егерменче елларда, башлыча, яңа мәктәпләр төзү, наданлыкны бетерү, кече яшь-тәге мәктәп балаларын башлангыч белем алуга тарту кебек эшләр башкарылды. Яңа тип мәктәпләр булдыру, укытуның яңа методларын эзләү, белем бирүне демократик нигезгә салу, яшьләрне хезмәткә әзерләүне һәм алар аңында пролетар идеология тәрбияләүне көчәйтү мәсьәләләре төп бурыч итеп куела. Утызынчы елларда инде мәктәпләрнең материаль базасы шактый ныгый, күп кенә дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр басылып чыга.

Милли мәктәпләрне методик кулланмалар белән тәэмин итүдә нәшриятлар һәм педагогик матбугат зур роль уйный. Менә бер генә мисал: I һәм II баскыч татар мәктәпләре өчен 1919 елның беренче яртысында Казанда 70 исемдә дәреслек бастырып чыгару

планлаштырыла. Алар арасында, мәсәлән, татар әдәбияты тарихы, әдәбият теориясе, Көнбатыш Европа әдәбияты тарихыннан очерклар, рус әдәбияты тарихы, Көнчыгыш әдәбияты тарихы, социологиядән хрестоматия, социализм тарихы, рус революциясе тарихы, геометрия, алгебра, тригонометрия, физика һ. б. дәреслекләр була. Профессиональ әзерлек буенча да дәреслекләр бастырыла. 1919 елда барысы 3 365 000 данә тираж белән 75 исемдә дәреслек һәм ярдәмлек бастырып чыгару күздә тотыла[7].

Газета һәм журнал битләрендә яңа методик рекомендацияләр, халык мәгарифе өлкәсендә дәүләтнең политикасы, укытуның яңа методлары һәм яңа орфография кагыйдәләре, ана теле һәм рус теле укыту мәсьәләләре турында дискуссион материаллар урнаштырыла. 1918 елда Казанда Бөек Октябрь социалистик революциясенең 1 еллыгына «Мәгариф» (хәзерге «Совет мәктәбе») журналының 1 нче саны чыга. Илебезнең төрле өлкәләрендәге татар мәктәпләре укытучылары аның һәр санын көтеп ала торган булганнар. Анда яңа программалар, методик күрсәтмәләр, мәктәптә эшне оештыру турында инструкцияләр урын алган.

Кырыгынчы-илленче елларда милли республикаларда педагогика фәне үсешенең төп үзенчәлеге алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм таратудан, мәктәпләр практикасындагы методик яңалыкларны педагогика фәне казанышларын искә алып куллланудан, хезмәткә өйрәтү һәм рус теле укытуның иң кулай юлларын эзләүдән гыйбарәт була.

Алтмышынчы-сиксәненче елларда исә мәктәпләр тарихын түгел, бәлки педагогик психология һәм педагогиканың теоретик проблемаларын өйрәнү күздә тотыла. Бүген педагог-галимнәр, КПССның XXV һәм XXVI съездлары карарларын кулланма итеп алып, түбәндәге проблемалар буенча тикшеренү эшләре алып баралар: укучыларда дөньяга фәнни караш тәрбияләү; хезмәт тәрбиясе, мәктәп балаларына политехник белем, профессиональ ориентация бирү; укучыларда актив тормыш позициясе тәрбияләү һәм аларны әдәп-

---

[7] Тутаев М. З. Октябрь һәм мәгариф (рус телендә). Казан, 1970, 409 б.

әхлакка өйрәтү; милли мәктәпләр, пионер оешмалары һәм халык мәгарифе тарихы; мәктәп һәм про-фессиональ-техник училище балаларының иҗади сәләтен, рационализаторлык һәм уйлап табу эшчәнлеген үстерү проблемалары; укытучы белән укучы арасындагы үзара мөнәсәбәтнең социаль-психологик аспектлары һ. б.

Милли мәктәпләрдә ана теле, рус теле һәм әдәбиятларын укыту методикасын эшкәртү педагогик тикшеренүләрнең аерым тармагын тәшкил итә. Бу өлкәдә милли республика педагоглары теоретик һәм практик тикшеренүләрдә зур уңышларта ирештеләр.

Милләтнең традициясе, тарихи тәҗрибәсе һәм яшәү шартларына бәйле рәвештә, кайбер республикаларда төп милләт халкыннан беренче педагогия фәннәре докторлары һәм беренче фәнни хезмәткәрләр 20 нче елларда ук барлыкка килә, ә икенчеләрен-дә исә фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен беренче диссертацияләр 30 нчы елларда, ә докторлык диссертацияләре 60—70 нче елларда гына яклана. Күренгәнчә, педагогика фәне өлкәсендә милли республикаларны тигезләү экономика өлкәсендә тигезләүгә караганда акрынрак барды. Моның сәбәбе дә бар. Чөнки «кеше формалаштыру, аны тәрбияләү турындагы фәннән дә кыенрак фән юк. Аны үзләштерү фикер тирәнлеген, аның рекоменацияләренә аналитик якын килүне һәм һәрьяктан укымышлы булуны таләп итә»[8]. Педагогика буенча докторлык диссертацияләренең әле хәзер дә зур читенлек белән генә яклануы очраклы түгел. Илебездәге педагогия институтларының тик өчтән берендә генә педагогия фәннәре докторлары булу да иң элек әнә шуның белән аңлатыла. Наданлыкка каршы көрәшнең беренче көннәрендә үк укытучылар җитешмәү проблемасы килеп баса. Россия губерналарында, шул исәптән татар мәктәпләрендә дә укытучылар җитешми. Ә Урта Азиядә алар бөтенләй диярлек булмый. Карандаш тота һәм иҗекләп укый белгән һәр кеше грамотага өйрәтү эшенә тартыла. Чөнки ул елларда башлангыч

[8] Прокофьев М. А. Советское просвещение навстречу 60-летию СССР — Советская педагогика, 1982, № 6, 10 б.

белемле укытучылар хәтта урта мәктәпләрдә дә бармак белән генә санарлык иде. Укытучылар әзерләү өчен оештырылган кыска сроклы курслар да сизелерлек нәтиҗә бирми. Шуңа күрә, союздаш һәм автономияле республикалар төзелү белән бергә, педагогия институтлары һәм техникумнары ачыла башлый.

Беренче татар революционерлары Х. Ямашев, Г. Колахметов, Г. Сәйфетдинов укыган татар укытучылар мәктәбе нигезендә 1919 елда Казан педагогия институты оештырыла.

Баштагы елларда анда татарлардан студентлар саны бик аз була. (Моның төп сәбәбе революциягә кадәр дөньяви мәктәпләрнең булмавы белән аңлатыла.) Мәсәлән, 1921 елда студентларның нибары 3 процентын татарлар, 7 процентын чувашлар тәшкил иткән. 1931 елда бу уку йорты Татар педагогия институты дип исемлән» башлый. Россия Федерациясендәге барлык татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү төп бурыч итеп куела. 1934 елдан ул Казан дәүләт педагогия институты дип йөртелә. Шәһәрләрдәге һәм район үзәкләрендәге татар мәктәпләре русча укытуга күчкәнлектән, татар мәктәпләре саны кимесә дә, студентларның яртысыннан күбрәген институт милли мәктәпләр өчен әзерли.

Совет власте елларында Педагогия институты 25 меңнән артык укытучы әзерләде. Алар арасында танылган укытучылар, галимнәр, журналистлар, язучылар, партия һәм совет работниклары бар. Институт чын мәгънәсендә милли кадрлар әзерләү үзәгенә әйләнде. Монда Советлар Союзы Герое Муса Җәлил укый, татарлардан беренче педагогия фәннәре докторлары профессор М. Х. Корбангалиен, РСФСР Педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты М. Ә. Фазлуллин, профессорлардан В. М. Горохов, Н. Надиев, О. Җ. Курмаен, М. И. Әл-мөхәмметов һәм башкалар белем ала. СССР Педагогия фәннәре академиясенең беренче президенты булып эшләгән В. М. Хвостов та заманында биредә укый.

Институтта фәнни тикшеренүләр нинди юнәлештә алып барыла соң? Беренче чиратта, болар — яңа совет мәктәбе теориясе, психология һәм

педагогика фәннәрен өйрәнүнең яңа системасына күчү, авыл мәктәпләрендә укыту-тәрбия процессын оештыру үзенчәлекләре, укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген үстерү, татар мәктәбендә рус теленә өйрәтүнең эчтәлеге һәм методикасы, укучыларга педагогик профессияләргә ориентация бирү. Институт галимнәре проблемалы укыту теориясен, Татарстан укытучыларының алдынгы тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерүгә дә зур әһәмият бирәләр.

Соңгы елларда профессорлардан Я. Хан-биковның «Татар халык педагогикасы тарихы», М. Мәхмүтовның «Проблемалы укыту теориясе һәм практикасы», Л. Шакированың «Татар мәктәбендә рус фигылен өйрәнү», Н. Половникованың «Укучыларның таньш-белү активлыгын һәм мөстә-кыйльлеген үстерү турында», М. Тутаевның «Октябрь һәм мәгариф», доцентлардан Җ. Вилькеевның «Мәктәптә укытканда фәнни танып-белү методлары» (фән нигезләрен проблемалы өйрәнү логикасы), А.Кирсановның «Укучыларның уку эшчәнлеген индивидуальләштерү» дигән күләмле монографияләре басылып чыкты.

Алдынгы педагогик тәҗрибәне гомумиләштерү һәм фәнни нигезләүдә галим-педагоглардан Р. А. Низамов, Г. Г. Жданова, И. И. Малкин, Н. М. Хәсәнов, Г. А. Петрова, Г. С. Закиров һәм башкаларның да тырыш хезмәтен билгеләп үтәргә кирәк.

Педагогик кадрлар әзерләүдә һәм Татарстанда педагогика фәнен үстерүдә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты галимнәренең дә өлеше зур. Революциягә кадәр- үк монда төрле фәнни мәктәпләр, шул исәптән профессор В. А. Богородицкийның телләрне өйрәнү методикасы мәктәбе барлыкка килә. 1944 елда биредә педагогика һәм татартеле кафедралары оештырыла. Аларда уку чыларга һәм студентларга эстетик тәрбия бирү, татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы өлкәсендә эшләүче зур белгечләр үсеп чыкты. Профессор Б. П. Рождественский эстетик тәрбия мәктәбе оеш-тырды, хәзер Казан дәүләт педагогия институты ректоры булып

эшләүче профессор М. 3. Зәкиев татар синтаксисын укытуметодикасына зур өлеш кертте, профессорД. Г. Тумашева татар теле морфологиясен өйрәнү методикасын эшләде.

Татарстанда педагогик тикшеренүләрнең өченче үзәге булып Алабуга педагогия институты (ректоры филология фәннәре докторы Т. Н. Галиуллин) санала. Авыл мәктәбендә пионер эшен оештыруның теоретик нигезләре — институтның педагогика кафедрасы әнә шул тема буенча тикшеренүләр алып бара.

Педагогия институтларыннан тыш, һәр союздаш республикада диярлек педагогика буенча фәнни-тикшеренү үзәкләре төзелә. (Шуларның берсе, Украинадагы Фәнни-тикшеренү институты турында берничә генә сүз әйтик: 1928 елда монда А. С. Мака-ренконың фәнни доклады тикшерелә. Пав-лыш мәктәбе директоры, соңыннан совет педагогикасы классигына әверелгән һәм СССР Педагогия фәннәре академиясенең член-корреспонденты итеп сайланган В. А. Сухомлннскин 1955 елда биредә кандидатлык диссертациясе яклый.) Автономияле республикаларда фәнни-тикшеренү үзәкләре исә РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының филиаллары формасында 60 нчы еллар башында ачыла. Татарстан филиалы 19Ы елда оештырыла. Аның беренче мөдире итеп милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасы өлкәсендә эшләүче иң зур белгечләрнең берсе Л. 3. Шакирова (хәзер Казан дәүләт педагогия институты профессоры, доктор) билгеләнә.

20 ел эчендә Филиалда күп кенә кадрлар үсеп чыкты, 5 докторлык диссертациясе әзерләнде һәм 10 нан артык кандидатлык диссертациясе якланды. Инде менә аңа озак еллар буе Г. Г. Жданова җитәкчелек итә. Филиал сотрудниклары 4 монография, 12 фәнни җыентык, 30 дан артык методик рекомендация, төрки мәктәпләр өчен 8 исемдә әлифба, рус һәм татар телләре дәреслекләре әзерләп чыгардылар. Барысы 400 басма табактан артыграк фәнни-методик продукция бастырылды.

Татарстандагы педагогик тикшеренүләрнең бишенче үзәге — СССР

Педагогия фәннәре академиясенең Профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү институты. 1976 елда гына ачылган бу фәнни үзәктә урта профессиональ-техник училище укучыларына белем һәм коммунистик тәрбия бирүнең гомуми проблемалары тикшерелә. Хәзергә ул — илебездә бу типтагы бердәнбер институт. Инде монда 150 дән артык фәнни работник, шул исәптән 55 тән артык доктор һәм фәннәр кандидаты — руслар, татарлар, эстоннар, украиннар, еврейлар, башкортлар һ. б. милләт вәкилләре эшли. Институт аспирантурасында 60 кеше укый. Махсус гыйльми советта гомуми һәм профессиональ-техник педагогика буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклана. Оештырылуына берничә генә ел булса да, Институт күп кенә фәнни хезмәтләр бастырып чыгарды. Мәсәлән: «Хәзерге дәрес. Теория мәсьәләләре» (М. И. Мәхмү-тов), «Яшь эшчеләрнең профессиональ фор-малашуы» (Р. В. Мөрсәлимов), «Профессиональ педагогикада тикшеренү методлары» (А. А. Кыверялг), «Укучыларга эшче профессиясенә ориентация бирү буенча мәктәп, профтехучилище һәм предприятиенең бергәләп эшләве» (А. А. Вайсбург), «Директор һәм мәктәп коллективы» (Р. Х. Шә-күров), «Остазлыкны оештыру» (Н. М. Та-ланчук һ. б.). Институт галимнәре Куба галимнәре белән бергәләп — бер, Чехословакия, Болгария һәм Польша коллегалары белән бергә ике китапның кульъязмасын әзерлиләр. Якындагы 5—6 елга Институт проф-техбелем системасының иң актуаль проблемалары буенча 10 докторлык, 54 кандидатлык диссертациясе әзерләүне бурыч итеп куйды.

Владимир Ильич элек артта калган халыкларны алга киткән халыклар дәрәҗәсенә күтәрү турында хыялланган иде. Бөек юлбашчының бу хыялы чынга ашты. Патша Россиясендә артта калган булып саналган казах, кыргыз, үзбәк һәм татар халкының хәзер «үз» галимнәре, «үз» профессорлары, үз флагы, гербы, үз конституциясе һәм хөкүмәте бар. Бу — һәркемне Европа культурасы дәрәҗәсенә генә түгел, бәлки яңа үргә — совет цивилизациясе биеклегенә күтәргән политик строй һәм мәгариф системасы җимеше.

Совет мәктәбенең казанышы кешеләрне ана телендә укырга һәм язарга өйрәтүдә, милли «масштабта» милли кадрлар тәрбияләүдә генә түгел. Совет мәктәбе һәм педагогикасының төп казанышларыннан берсе шунда: ул, пролетар интернационализм принципларын кулланып, дуслык һәм үзара аңлашу, коллективизм рухында, формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булган теләсә нинди культурага ихтирам рухында берничә буын совет яшьләрен тәрбияли алды.